Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылы
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 14.11.2019 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылы халык җыены нәтиҗәләре турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Александровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2020 елда үзара салым акчасын 250 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

- Татар Карамалысы торак пунктында Сабантуй, Яңа Ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр, призлар сатып алу;

- Татар Карамалысы торак пунктында корыган, кипкән агачларны кисеп, урам чистарту;

“ӘЙЕ ЮК”

соравы буенча 2019 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, 2019 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 237 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 190 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 181 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә булды:

1. Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Александровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2020 елда үзара салым акчасын 250 сум күләмендә

кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

- Татар Карамалысы торак пунктында Сабантуй, Яңа Ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр, призлар сатып алу;
- Татар Карамалысы торак пунктында корыган, кипкән агачларны кисеп, урам чистарту;

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга («әйе» - 181, «юк»-0).

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Татар Карамалысы авылы, Совет урамы 49 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А.Н.Еремин